КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 30 март г.Казань № 250

Югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укытуга кабул итү квоталарын билгеләү тәртибен һәм вакытларын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль законның $71^1$ статьясындагы 3 өлеш, «Мәгариф турында» 2013 ел, 22 июль, ТРЗ-68 нче Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешнең $15^1$ нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы икътисадының квалификацияле кадрларга ихтыяҗларын тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укытуга кабул итү квоталарын билгеләү тәртибен һәм вакытларын расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.
3. Бу карарның гамәле 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 30 март, 250 нче
карары белән расланды

## Югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укытуга кабул итү квоталарын билгеләү тәртибе һәм вакытлары

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан югары белем бирүче мәгариф оешмаларына (алга таба – мәгариф оешмасы) Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән дәүләт аккредитациясе булган югары белем бирүнең мәгариф программалары (бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада фәнни-педагог кадрлар әзерләү программалары) буенча максатчан укытуга кабул итү квоталарын (алга таба – максатчан укытуга кабул итү квотасы) билгеләү механизмын һәм вакытларын билгели.

2. Максатчан укытуга кабул итү квотасы ел саен, Татарстан Республикасы икътисадының квалификацияле кадрларга ихтыяҗларын исәпкә алып, мәгариф оешмасы өчен расланган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укытуга кабул итүнең контроль саннары (алга таба – кабул итүнең контроль саннары) чикләрендә югары белем бирүнең һәр дәрәҗәсе, һәр белгечлек һәм һәр әзерлек юнәлеше буенча билгеләнә.

3. Максатчан укытуга кабул итү квотасы мәгариф оешмасы тарафыннан әзерлек юнәлешләре һәм белгечлекләр буенча билгеләнә, аларның исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 ел, 11 февраль, б-186 нчы боерыгы белән раслана.

4. Максатчан укытуга кабул итү квотасы мәгариф оешмасы тарафыннан һәр белгечлек һәм укыту формалары детальләштерелеп күрсәтелгән әзерлек юнәлеше буенча тулаем билгеләнә. Мәгариф оешмасы квотаны мөстәкыйль рәвештә әзерлек юнәлеше (белгечлек) кысаларында бүлеп бирелә торган белем бирү программалары арасында бүлә.

5. Максатчан укытуга кабул итү квотасын билгеләү максатларында, мәгариф оешмасы ел саен, агымдагы елның 20 апреленә кадәр, агымдагы елда максатчан укытуга кабул итүнең планлаштырыла торган күләмнәре турындагы мәгълүматларны бу Тәртипкә теркәлгән кушымтада бирелгән форма буенча Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына кертә.

6. Әзерлекнең (белгечлекнең) һәр юнәлеше буенча кабул итүнең контроль саннарының гомуми саныннан 10 процентка артыграк булган күләмдә бирелгән квота мәгариф оешмасының гомуми аналитик хатында (гомуми күләме өч биттән артмаган, ирекле формада язылган) өстәмә рәвештә нигезләнә. Аналитик хатка максатчан укытуга кабул итү квотасын 10 проценттан артыграк билгеләүне нигезли торган документлар (максатчан укыту турындагы шартнамәләр күчермәләре, алар булмаган очракта – органнарның яки оешмаларның максатчан

укыту турында шартнамәләр төзү буенча тәкъдимнәр хакындагы хатлары күчермәләре) өстәмә рәвештә кертелә.

7. Әзерлекнең (белгечлекнең) һәр юнәлеше буенча кабул итүнең контроль саннарының гомуми санынан 10 проценттан артмаган күләмдә бирелгән квота өстәмә нигезләүләр таләп итми.

8. Мәгариф оешмасы җитәкчесенең имзасы һәм мөһере белән расланган максатчан укытуга кабул итүнең планлаштырыла торган күләмнәре турындагы мәгълүматлар мәгариф оешмасы тарафыннан Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына рәсми рәвештә җибәрелә.

9. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәгариф оешмасыннан хат алган көннән 10 эш көне эчендә кертелгән документларны карап тикшерә, агымдагы уку елына максатчан укытуга кабул итү квотасын раслау турындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы проектын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертә.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ел саен, агымдагы елның 1 июненнән дә соңга калмыйча, агымдагы уку елына максатчан укытуга кабул итү квотасын билгели.

Югары белем бирүче мәгариф оешмаларына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирүнең мәгариф программалары буенча максатчан укытуга кабул итү квоталарын билгеләү тәртибенә һәм вакытларына
кушымта

Форма

________________________________________________________________

(югары белем бирүче мәгариф оешмасының тулы исеме)

20__/20__ уку елына билгеләнгән Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән югары белем бирү белгечлекләре һәм әзерлек юнәлешләре буенча кабул итүнең максатчан саннары чикләрендә югары белем бирүнең мәгариф программалары (бакалавриат программалары, специалитет программалары, магистратура программалары, аспирантурада фәнни-педагог кадрлар әзерләү программалары) буенча максатчан укытуга кабул итүнең планлаштырыла торган күләмнәре турында мәгълүматлар

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды һәм исеме[1] | Укыту формасы | Нигезләү[2] | 20__/20__ уку елына кабул итүнең билгеләнгән контроль саннары күләме | 20__/20__ уку елында максатчан укытуга кабул итү өчен планлаштырыла торган урыннар саны | 20__/20__ уку елына кабул итүнең билгеләнгән контроль саннарыннан максатчан кабул итүнең планлаштырыла торган квотасы, процент |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |

Җитәкче М.У. ______________ (имзасы) ____________ (Фамилиясе, Исеме, Атасының исеме)

________________________________________

[1] Әзерлек һәм белгечлек юнәлешләре Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел, 12 сентябрь, 1060 һәм 1061 нче боерыклары белән расланган югары белем бирүнең әзерлек юнәлешләре һәм белгечлекләре исемлекләре нигезендә күрсәтелә.

[2] Максатчан укыту турындагы шартнамәләрнең реквизитлары, ә алар булмаганда – органнарның һәм оешмаларның максатчан укыту турында шартнамәләр төзү буенча тәкъдимнәр хакындагы хатлары реквизитлары күрсәтелә.